КАБИНЕТ МИНИСТРОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

2020 ел, 23 ноябрь г.Казань № 1052

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының кайбер карарларына үзгәрешләр кертү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасында күп балалы гаиләләргә социаль ярдәм күрсәтү буенча өстәмә чаралар турында» 1992 ел, 28 декабрь, 708 нче карарына (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 1999 ел, 3 август, 476 нчы; 2004 ел, 17 декабрь, 540 нчы; 2007 ел, 6 декабрь, 693 нче; 2012 ел, 23 июнь, 545 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып), 4 нче пунктның беренче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«4. Татарстан Республикасы законнары нигезендә күп балалы гаиләнең социаль ярдәм чараларыннан файдалануга хокукын раслый торган документ булып Татарстан Республикасы Хезмәт, халыкны эш белән тәэмин итү һәм социаль яклау министрлыгының территориаль органы тарафыннан аның салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булмаганда ата-ананың (уллыкка алучыларның) берсенә бирелә торган күпбалалы гаилә таныклыгы тора дип билгеләргә.».

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Гаиләләргә бер үк вакытта өч һәм аннан да күбрәк бала туганда пособиеләр билгеләү һәм түләү тәртибе турындагы нигезләмәне раслау хакында» 2008 ел, 17 ноябрь, 814 нче карары белән (Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2013 ел, 19 гыйнвар, 20 нче; 2013 ел, 12 март, 157 нче; 2014 ел, 11 август, 579 нчы; 2015 ел, 19 май, 355 нче; 2017 ел, 1 ноябрь, 833 нче карарлары белән кертелгән үзгәрешләрне исәпкә алып) расланган Гаиләләргә бер үк вакытта өч һәм аннан да күбрәк бала туганда пособиеләр

билгеләү һәм түләү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

5 нче пунктка түбәндәге эчтәлекле «д» пунктчасын өстәргә:

«д) бу Нигезләмәнең 3 нче пунктында күрсәтелгән гражданның салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлары булганда.»;

7 нче пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын файдаланып электрон рәвештә, бер тапкыр түләнә торган пособиене билгеләү турында карар кабул итү өчен балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар, балаларны опекага алуны билгеләү, балаларны тәрбиягә бала алган гаиләгә тәрбияләүгә тапшыру, салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмавы турында мәгълүматлар ала.»;

10 нчы пунктның җиденче абзацын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Бүлек ведомствоара соратулар нигезендә, шул исәптән ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек системасын файдаланып электрон рәвештә, ай саен түләнә торган пособиене билгеләү турында карар кабул итү өчен балалар тууын дәүләт теркәвенә алу турында мәгълүматлар, балаларны опекага алуны билгеләү, балаларны тәрбиягә бала алган гаиләгә тәрбияләүгә тапшыру, салымнар, җыемнар һәм Россия Федерациясе бюджет системасы бюджетларына башка мәҗбүри түләүләр буенча бурычлар булмавы турында мәгълүматлар ала.»;

Татарстан Республикасы
Премьер-министры А.В.Песошин